ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы турында

Хезмәтне саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру максатларында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, "Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында" Татарстан Республикасы законы таләпләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында" 2008нче елның 10нчы ноябрендәге 799нчы номерлы карары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Уставына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы каршындагы Хезмәтне саклау буенча Координацион совет булдырырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы турында Нигезләмәне расларга (1нче кушымта)

3. Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы Составын расларга (2нче кушымта)

4. Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының 2012нче елның 28нче мартыннан 22а номерлы «Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы каршындагы Хезмәтне саклау буенча Координацион совет турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга (2020нче елның 22нче октябрендәге 94нче номерлы үзгәрешләре белән).

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зыятдинов

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының
2021нче елның _____ №____ карарына

1нче кушымта

## Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы каршындагы Хезмәтне саклау буенча Координацион совет турында Нигезләмә

1. Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы каршындагы Хезмәтне саклау буенча Координацион совет (алга таба - Совет) Югары Ослан муниципаль районында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында төзелә.

2. Совет җирле үзидарә органнарының эш бирүчеләр, оешмаларның хезмәтне саклау хезмәтләре, хезмәтне саклау, күзәтчелек һәм контроль өлкәсендә дәүләт идарәсе органнары, социаль иминият фонды, һөнәр берлекләре берләшмәләре һәм башка иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлегендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

3. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, хезмәтне саклау өлкәсендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының закон һәм башка норматив-хокукый актлары, Югары Ослан муниципаль районы Уставы, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Советның төп бурычлары булып торалар:

хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру эшчәнлеген координацияләү;

эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау таләпләрен үтәвен контрольдә тоту;

хезмәткәрләрнең эш урыннарында куркынычсыз шартларга һәм хезмәтне саклауга хокукларын яклау;

төрле милек формасындагы оешмаларда хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау торышын анализлау һәм аларны яхшырту буенча чаралар күрү;

хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программаларны эшләү һәм кабул итү;

оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләре, хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органнары, оешмалар һәм лабораторияләр, фәнни оешмалар, медицина учреждениеләре, хезмәтне саклау буенча уку үзәкләре, шулай ук хезмәтне саклау буенча башка чаралар катнашында семинарлар, киңәшмәләр, "түгәрәк өстәлләр", "хезмәтне саклау көннәре" үткәрү;

барлык оештыру - хокукый формадагы һәм милек рәвешләрендәге оешмалар арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга смотр - конкурслар үткәрү.

5. Совет үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә:

хезмәтне саклау буенча гамәлдәге законнарны гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләрне карый;

хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программаларны эшләү өчен эшче төркемнәр булдыра;

хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программаларны тормышка ашыруны контрольдә тота;

шартларның һәм хезмәтне саклауның торышын өйрәнү һәм анализлау һәм аларны яхшырту буенча чаралар күрү максатларында төрле милек рәвешләрендәге оешмалар советы әгъзаларына баруны планлаштыра;

эш бирүчеләр тарафыннан хезмәткәрләргә авыр эш, зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эш өчен компенсацияләр, шул исәптән сөт яисә

башка бертигез кыйммәтле азык-төлек продуктлары бирүнең дөреслеге мәсьәләләрен карый;

хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыру буенча смотр-конкурсларда барлык оештыру-хокукый формадагы оешмаларның катнашуын оештыра;

барлык оештыру-хокукый формадагы һәм милек рәвешләрендәге оешмалар арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыру смотр-конкурсларында җиңүчеләрне билгели;

хезмәтне саклау һәм җитештерү санитариясе өлкәсендә профилактика эшенең алдынгы методларын һәм формаларын кертү мәсьәләләре буенча оешмаларга ярдәм итә;

50дән артык кеше эшли торган оешмаларда хезмәтне саклау хезмәтләрен булдыруга ярдәм итә;

төркемле бәхетсезлек очракларының, үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очракларының сәбәпләрен һәм аларны бетерү буенча күрелә торган чараларны карый;

күзәтчелек һәм контроль органнары тарафыннан производство травматизмы, авариялелек һәм һөнәри авырулар санының югары дәрәҗәсенә ия булган оешмаларда үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләрен карый;

хезмәт шартлары буенча эш урыннарын аттестацияләүне активлаштыруга, киләчәктә хезмәтне саклау буенча эшләрне сертификацияләүгә, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларда хезмәт шартлары буенча аттестация үткәрүне активлаштыруга ярдәм итә;

үз утырышларында эш бирүчеләрнең производство травматизмы һәм һөнәри авыруларны кисәтү, эш урыннарында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча күрелә торган чаралар турында тыңлый;

Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе, Прокуратура, Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор, башка күзәтчелек һәм контроль органнарына хезмәтне саклау турындагы закон таләпләрен бозган эш бирүчеләргә карата чаралар күрү, производство травматизмы һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсе югары булган эш бирүчеләргә карата чаралар күрү турында тәкъдимнәр кертә;

муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенә эш урыннарында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча уңай тәҗрибәгә ия булган, куркынычсыз технологияләр һәм җитештерү чараларын кертә торган эш бирүчеләрне бүләкләү турында тәкъдимнәр кертә;

оешмаларда хезмәтне саклау буенча күмәк шартнамәләр һәм килешүләр төзү, хезмәтне саклау буенча җитәкчеләр һәм белгечләрне укыту, хезмәткәрләрне махсус кием, махсус аяк киеме һәм башка шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү буенча эшләрнең агымдагы торышын тикшерә;

хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча илебезнең һәм чит илләрнең алдынгы тәҗрибәсен таратуга ярдәм итә.

6. Совет рәисе - муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе.

7. Совет составы муниципаль район Башлыгы карары белән раслана. Совет составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, төрле милек формасындагы оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләре, Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе, Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор, Социаль иминият фондының җирле органнары, профсоюзлар һәм башка иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә ала (килешү буенча).

8. Совет үз эшчәнлеген Совет утырышында кабул ителә һәм муниципаль район башлыгы тарафыннан раслана торган эш планы нигезендә гамәлгә ашыра.

9. Совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

10. Совет утырышлары кварталга кимендә 1 тапкыр үткәрелә.

11. Совет карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм Совет утырышында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, алар өчен кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

12. Совет утырышлары рәис һәм сәркатип тарафыннан имзаланган беркетмәләр рәсмиләштерелә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының
2021нче елның
___№____ карарына
2нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы Составы

Совет Рәисе:

| | |
|---|---|
| Шакиров Илнур Ирек улы | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Сәркәтип: | |
| Минһаҗева Әлфия Корбангали кызы | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе (килешү буенча) |
| Совет әгъзалары: | |
| Габдрахманова Алинә Рим кызы | «Югары Ослан муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Рәшит Галимҗан улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының Югары Ослан муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Пестов Эдуард Валериевич | "Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 112 нче янгын бүлеге " Дәүләт учреждениесе башлыгы (килешү буенча) |
| Борһанов Альберт Шамил улы | Югары Ослан районы буенча Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясенең бүлек башлыгы (килешү буенча) |
| Смирнов Алексей Олегович | «Югары Ослан үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы (килешү буенча) |
| Агеева Екатерина Константиновна | Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Яшел Үзән районы һәм Зеленодольск шәһәре территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| | "Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тәэмин итү идарәсе" МКУ хезмәтне саклау буенча баш белгеч –вәкиле |
| Гущенкова Ольга Викторовна | Баш белгеч-Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе дәүләт учреждениесе вәкиле (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Хөрмәтуллина Лилия Илфар кызы | Контроль-хисап палатасы рәисе, профсоюз оешмаларының координация советы рәисе (килешү буенча) |
| Наумова Татьяна Вениаминовна | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Югары Ослан муниципаль районы буенча җәмәгать ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Шәмсетдинов Рунар Рафыйк улы | Россия Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенең Югары Ослан районара тикшерү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Касыймов Вилен Вакыйф улы | "Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге" МКУ начальнигы (килешү буенча) |
| Муфталиев Нусрат Заһид улы | "Татмедиа" ААҖ филиалы "Волжская Новь" газетасы редакциясе баш мөхәррире (килешү буенча) |